# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегенең Печищи авылында 2026 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

2025 елның 30 ноябре №20

«Халык хакимиятенең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены
КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегенең Печищи торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түбәндәге категория гражданнардан тыш, 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертергә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;
б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.
в) СВО катнашучылары гаиләләре

Аерым категория гражданнар өчен:
а) 1нче төркем инвалидлар,
б) күп балалы гаиләләр,
в) көндезге уку йортлары студентлары,
түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Печищи авылының гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы җиһазларын сатып алу).

. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Печищи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы В.Н. Журкин